ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**01.09.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1607**

«Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 июнендәге 1367 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 07 декабрь, 2502 нче , 2019 ел, 14 февраль, 355 нче , 2019 ел, 30 октябрь, 2308 нче , 2019 ел, 16 ноябрь, 2465 нче, 2020 ел,13 май, 805 нче, 2020 06 июль, 1208 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта);

1.2.Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә расларга (2 нче кушымта);

1.3.Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (3 нче кушымта).

2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль норматив актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р. З. Хаҗиевка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына кушымта
01.09.2020 ел №1607

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә), хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмен, шулай ук аларның критерийларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт түләү системасы - оешма хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база (вазыйфаи) окладлары күләмнәрен дә кертеп, билгели торган нормалар җыелмасы, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

база оклады - оешма хезмәткәренең календарь ае өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен яисә хезмәт нормасы (хезмәт хакы нормасы) өчен билгеләнгән, башкарыла торган эшләрнең авырлыгына бәйле рәвештә, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпкә алмыйча, оклад, хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - хезмәткәрләренең хезмәт (вазыйфаи) бурычларын, компенсация, стимуллаштыра торган һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, асылда (фактик) эшләнгән вакыт өчен, календарь ае өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

эш хакы (хезмәткәрнең хезмәт хакы) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм эшнең шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре

компенсация характерындагы түләүләр - компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормадан читкә тайпылган шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка мактау түләүләре (поощерительные выплаты).

3. Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәткәрләрнең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

вазыйфаи окладлары;

компенсация характерындагы түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр.

4. Хезмәткәрнең юнәлеш буенча эш стажы артуга, белем алу буенча яисә белем алу турында документлар торгызылуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, ведомствоның аерым билгеләре белән бүләкләүгә, еллык яисә башка отпускта булган чорда, аның вакытлыча хезмәткә яраксызлыгы чорында, шулай ук аның эчендә уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда хезмәт хакы арттырылуга бәйле хезмәт хакы күләмен үзгәртү хокукы барлыкка килгәндә, аның хезмәте өчен түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәрә.

5. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

педагогик хезмәткәрләрнең белеме турындагы документларны (билгеле бер вазыйфада белгечлек буенча эшен) һәм педагогик стажын, һәм педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (вазыйфаи окладлары) күләме билгеләнә торган башка нәрсәләрне тикшерә;

ел саен гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзи һәм раслый;

гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

6. Гомуми белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы:

ел саен гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә уку елы башына тиешле окладларны раслый;

гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүне гамәлгә ашыра, аның нигезендә аларга стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели.

## II. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем бирү | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациял әрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Әйдаман | 9 489 | - | - |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | 9 489 | - | - |
| | Укыту бүлеге секретаре | 9 489 | 9 868 | - |
| Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча дежур | - | 10 015 | 10 020 |
| | Кече тәрбияче | 9 550 | 10 015 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф оешмасы диспетчеры | - | 10 273 | 10 280 |
| | Режим буенча өлкән дежур | | | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт белеме буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыкаль җитәкче | | | |
| | Өлкән әйдаман | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | - | 11 687 | 14 220 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | | | |
| | Оештыручы педагог | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| | Тренер-укытучы | | | |
| | Методист- инструктор | - | - | 14 220 |
| Өченче квалификация | Тәрбияче | - | 11 693 | 14 232 |
| | Производствога өйрәтү | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәрәҗәсе | мастеры<br>Педагог-психолог | | | |
| | Өлкән методист-инструктор | - | - | 14 232 |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | - | - | 14 232 |
| | Өлкән тренер-укытучы | - | - | 14 232 |
| | Методист | - | - | 14 232 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы (укытучы-профессор- составына кертелгән укытучылар вазыйфаларыннан тыш)<br>Тормыш иминлеге нигезләрен оештыручы укытучы<br>Физик тәрбия җитәкчесе<br>Укытучы | - | 11 695 | 14 236 |
| | Өлкән тәрбияче | - | - | 14 236 |
| | Әйдәп баручы методист | - | - | 14 236 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү | - | - | 14 236 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | | | |
| | Укытучы-дефектолог | - | - | 14 236 |
| | Логопед-укытучы (логопед) | - | - | 14 236 |
| | Педагог-китапханәче | - | - | 14 236 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар, гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә (бүлек, лаборатория, бүлек, сектор, укытуконсультация пункты, укыту-җитештерү остаханәсе һәм башка | - | - | 14 301 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | структур бүлекчәләр) мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту-җитештерү остаханәсе, уку-укыту (уку-җитештерү) остаханәсе, уку-укыту хуҗалыгы башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) һәм башкалар | - | - | 14 364 |

2. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | База окладының аена күләме, сум | |
|---|---|---|
| | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем бирү | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Аккомпаниатор | 10 000 | 10 300 |
| Мәдәни чаралар оештыручы | | |
| «Әйдәп баручы звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» | | |
| Китапханәче | 10 500 | 13 000 |
| Тавыш операторы | | |
| Әйдәп баручы китапханәче | | |
| Рәссам-декоратор | | |
| Баш китапханәче | | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 11 700 | 14 300 |

| | | |
|---|---|---|
| Музейның бүлек (сектор) мөдире | | |

3. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 9 489 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 10 000 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы | 10 500 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 11 000 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 11 700 |
| | Процедуралар буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 12 700 |
| | Здравпункт мөдире-фельдшер (шәфкать туташы) | |

| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр - (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 14 200 |

4. Эшкә алынучының белем дәрәҗәсе җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе белән билгеләнгән дәрәҗәдән түбәнрәк яки һөнәри стандартлардан түбәнрәк булган очракта, мондый хезмәткәрләргә база оклады таләп ителгән тиешле белем дәрәҗәсе нигезендә билгеләнә.

5. Эшкә алынучының белем дәрәҗәсе җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе белән билгеләнгән дәрәҗәдән югарырак яки һөнәри стандартлардан югарырак булган очракта, мондый хезмәткәрләргә база оклады таләп ителгән тиешле белем дәрәҗәсе нигезендә билгеләнә .

## III. Мәгариф хезмәткәрләренең эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр саны һәм хезмәт күрсәтүләрнең норматив саны.

1. Эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагогика хезмәткәрләренең эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) турында һәм хезмәт шартнамәсендә килешенгән педагогика хезмәткәрләренең укыту йөкләмәсен билгеләү тәртибе хакында» 2014 ел, 22 декабрь, 1601 нче боерыгы белән билгеләнгән.

Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) атнага 36 сәгатьтән дә артык булмаган кыскартылган эш вакыты дәвамлылыгыннан чыгып билгеләнә, ул мөгаллимлек (уку) эшен, тәрбияви эшне, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимы белән каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.

2. Хезмәт хакы ставкасы өчен укытучылар (педагогик) эше нормасы түбәндәгечә билгеләнә:

физик тәрбия җитәкчеләренә, укытучы- оештыручыга (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә кадәр әзерлек буенча) елына 360 сәгать күләмендә;

белем алучылар саны 50 кешегә кадәр булган башлангыч гомуми белем бирү оешмалары директорларына (педагогик колледжлар студентларының педагогик практикасын узу өчен беркетелгән башлангыч гомуми белем бирү

оешмаларыннан тыш), укучылар саны 80 кешегә кадәр булган кичке (шәһәр тибындагы шәһәрләрдә һәм поселокларда - 100 кешегә кадәр) гомуми белем бирү оешмалары директорларына атнасына 10 сәгать күләмендә;

Мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

3. Мәгариф хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүнең норматив саны хезмәт хакының база ставкасы (база оклады) сәгатенә тәшкил итә:

3.1. Укытучылар, мөгалимнәр, хезмәт инструкторлары, производствога өйрәтү мастерлары, физик тәрбия җитәкчеләре, тормыш иминлеге һәм хәрби хезмәткә әзерлек нигезләре укытучы-оештыручылары:

25 кеше - гомуми белем бирү программасын һәм гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы шәһәр гомуми белем бирү оешмалары (шул исәптән гимназияләр, лицейлар, кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәпләре сыйныфларында, бер яисә берничә предмет буенча белем алучыларны өстәмә (тирәнтен) әзерләүне тәэмин итә торган сыйныфларда;

20 кеше - интернат, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем, шул исәптән аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче, гимназия-интернатлар, лицей-интернатлар, шәһәр санатор белем бирү оешмалары, интернат булган шәһәр санатор-урман мәктәпләре, кадет интернат-мәктәпләре, кадет интернат-мәктәпләре классларында белем алучылар;

15 кеше - интернаты булган авыл шифаханә-белем бирү оешмалары, авыл шифаханә-урман мәктәпләре, гомуми белем бирү программасын һәм гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы авыл кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәпләре сыйныфларында, бер яисә берничә предмет буенча өстәмә (тирәнтен) әзерләүне тәэмин итә торган авыл шифаханә-белем бирү оешмалары сыйныфларында;

14 кеше - гомуми белем бирү программасын һәм гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы авыл гомуми белем бирү оешмалары (шул исәптән гимназияләр һәм лицейлар) сыйныфларында, алар бер яисә берничә предмет буенча өстәмә (тирәнтен) әзерләүне тәэмин итә торган сыйныфларда;

10 кеше - девиант тәртипле укучылар өчен махсус гомуми белем бирү мәктәпләренең (укыту-тәрбия учреждениеләренең) сыйныфларында (төркемнәрендә);

9 кеше - кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәпләрен читтән торып уку рәвешендәге төркемнәрдә.

Гомуми белем бирүнең беренче, икенче һәм өченче баскычларында милли телле гомуми белем бирү оешмаларында чит тел, туган тел һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты дәресләрен үткәргәндә, гомуми белем бирүнең беренче, икенче һәм өченче баскычларында хезмәт укытканда, гомуми белем бирүнең өченче баскычында физик тәрбия, информатика һәм хисаплау техникасы, физика һәм химия (практик дәресләр вакытында) буенча дәресләр үткәрелгәндә, сыйныфның тулылыгы 25 кеше булса, шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында һәм авыл җирлегендә кимендә 20 кеше булса сыйныфны ике төркемгә бүлү рөхсәт ителә.

Гомуми белем бирү оешмаларында, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен - 5 кеше:

I төр- психик үсеше тоткарланган яки акылы зәгыйфь чукрак балалар өчен;

II төр- ишетү сәләте бозылу һәм акыл зәгыйфьлеге аркасында, сөйләм үсеше нык тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

II төр- ишетү сәләте бозылу һәм психик үсеше тоткарланган аркасында, сөйләм үсеше нык тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

III төр- психик үсеше тоткарланган сукыр балалар өчен;

III төр- акылы зәгыйфь сукыр балалар өчен;

IV төр- акылы зәгыйфь начар күрүче һәм соң сукырайган балалар өчен;

VI төр- терәк-хәрәкәтләнү аппараты бозылган һәм акыл зәгыйфьлеге булган балалар өчен;

Гомуми белем бирү оешмалары өчен, гомуми белем бирү оешмаларының махсус (коррекцион) сыйныфларында - 6 кеше:

I төр-чукраклар өчен;

II төр- ишетү сәләте бозылу аркасында, сөйләм үсеше нык тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

Сукыр балалар өчен III төр гомуми белем бирү оешмалары, иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган укучылар,физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр(психик үсеше тоткарланган яки акылы зәгыйфьле җиңелчә формалары булган) гомуми белем оешмалары өчен -8 кеше.

Гомуми белем бирү оешмалары өчен, гомуми белем бирү оешмаларының махсус (коррекцион) сыйныфларында -10 кеше:

II төр- ишетү сәләте бозылу аркасында, сөйләм үсеше җиңелчә тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

VI төр- терәк-хәрәкәтләнү аппараты бозылган балалар өчен;

VIII төр- акылы нык зәгыйфь балалар өчен ;

Гомуми белем бирү оешмалары өчен, гомуми белем бирү оешмаларының махсус (коррекцион) сыйныфларында -12 кеше:

IV төр - начар күрүче һәм соң сукырайган балалар өчен;

V төр - сөйләм үсеше нык бозылган балалар өчен;

VII төр -психик үсеше тоткарланган балалар өчен;

VIII вида - акылы зәгыйфь балалар өчен;

Шәһәр җирлегендә булган, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен, шифаханә белем бирү оешмалары өчен -20 кеше;

Авыл җирендә булган,озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен, шифаханә белем бирү оешмалары өчен-15 кеше.

Хезмәтне укыту, социаль-көнкүреш юнәлеше дәресләре, факультатив үткәргәндә сыйныф ике төркемгә бүленә. Төркемнәргә бүлгәндә кызлар һәм малайлар өчен хезмәт укыту профиле, шулай ук белем бирү оешмаларының төре исәпкә алына.

3.3. Белем бирү оешмаларының озынайтылган көне төркемнәре тәрбиячеләренә-25 кеше.

3.4. Гомуми белем бирү оешмаларында, интернаты булган белем бирү оешмаларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен мәгариф оешмаларында, гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләргә:

20 кеше - гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта, интернаты булган гомуми белем бирү оешмасында;

10 кеше - озак вакытлы дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шәһәр шифаханә белем бирү оешмасында;

7 кеше - озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен авыл шифаханә белем бирү оешмасында;

5 кеше - махсус гомуми белем бирү мәктәбе (девиант тәртипле укучылар өчен укыту-тәрбия оешмасы), интернат булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

I төр- психик үсеше тоткарланган яки акылы зәгыйфь чукрак балалар өчен;

II төр- ишетү сәләте бозылу һәм акыл зәгыйфьлеге аркасында, сөйләм үсеше нык тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

II төр- ишетү сәләте бозылу һәм психик үсеше тоткарланган аркасында, сөйләм үсеше нык тоткарланган начар ишетүчеләр һәм соң чукракланучылар өчен;

III төр- психик үсеше тоткарланган сукыр балалар өчен;

III төр- акылы зәгыйфь сукыр балалар өчен;

IV төр- акылы зәгыйфь начар күрүче һәм соң сукырайган балалар өчен;

VI төр- терәк-хәрәкәтләнү аппараты бозылган һәм акыл зәгыйфьлеге булган балалар өчен;

Иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен (психик үсешне тоткарлау һәм акыл зәгыйфьлеге җиңел формалары) гомуми белем бирү оешмалары өчен-4 кеше;

6 кеше - интернаты булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

I төр - чукрак балалар өчен;

II төр - ишетү сәләте бозылу сәбәпле, сөйләме нык тоткарланган, начар ишетүче һәм соңрак саңгырауланган балалар өчен;

8 кеше - III төр гомуми белем бирү оешмаларында сукырлар өчен;

10 кеше - гомуми белем бирү оешмаларында, гомуми белем бирү оешмаларында махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен:

II төр - ишетү сәләте бозылу сәбәпле, сөйләме җиңелчә тоткарланган һәм начар ишетүче балалар өчен;

VI төр - терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен;

VIII төр - тирән акылга зәгыйфь балалар өчен;

12 кеше - интернат булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

VI төр - начар күрүчеләр һәм соңрак сукырайган балалар өчен;

V төр - сөйләме авыр булган балалар өчен;

VII төр - психик үсешләрендә тоткарлык булган балалар өчен;

VIII төр - акылга зәгыйфь балалар өчен.

3.5. Үсешләрендә тайпылышлары булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар (тәрбияләнүчеләр) төркемнәрендә эшләүче өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, укытучы-дефектологлар, логопед, педагог-психологлар, кече тәрбиячеләр, тәрбиячеләрнең ярдәмчеләре:

өч яшькә кадәрге балалар төркемнәрендә:

катлаулы дефектлы балалар өчен (физик һәм (яки) психик үсештәге ике яки аннан да күбрәк җитешсезлекләргә ия булган)- 5 кеше;

чукраклар, сукырлар, сөйләм үсеше нык тоткарланганнар, начар ишетүчеләр, күзләре начар күрүче балалар, амблиопияле, кылый күзле балалар, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, җиңел дәрәҗәдә акылга зәгыйфь, психик үсеше тоткарланган балалар өчен- 6 кеше;

туберкулез интоксикациясе булган, еш авыручы, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен-10 кеше;

махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган, башка категория балалар өчен-12 кеше;

өч яшьтән өлкәнрәк балалар төркемнәрендә:

аутизмлы балалар, катлаулы дефектлы (физик һәм (яки) психик үсешендә ике яки аннан да күбрәк җитешсезлекләре булган) балалар өчен - 5 кеше;

чукрак, сукыр балалар өчен-6 кеше;

начар ишетүче, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, акыл зәгыйфьлеге уртача, авыр балалар өчен-8 кеше;

психик үсеше тоткарланган балалар, сөйләм үсеше нык тоткарланганнар, күзләре начар күрүче балалар, амблиопияле, кылый күзле балалар, җиңел дәрәҗәдә акылга зәгыйфь балалар өчен-10 кеше ;

12 кеше - фонетик-фонема сүз тайпылышлары булган балалар өчен;

туберкулез интоксикациясе булган, еш авыручы, физик мөмкинлекләре чикләнгән, махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган, башка категория балалар өчен -15 кеше;

3.6. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркемнәрендә балалар белән эшләүче (тәрбияләнүчеләре белән) өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, укытучы-дефектологлар, логопед, педагог-психологлар, кече тәрбиячеләргә, тәрбиячеләрнең ярдәмчеләренә:

балалар төркемнәрендә:

ике айдан бер яшькә кадәр-10 кеше;

бер яшьтән өч яшькә кадәр-15 кеше;

өч яшьтән җиде яшькә кадәр-20 кеше;

төрле төркемнәрдә:

ике яшьтәге (ике айдан өч яшькә кадәр) балалар төркемендә булганда-8 кеше;

төркемдә өч яшькә кадәрге (өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге) балалар булганда-10 кеше;

төркемдә ике яшьтәге (өч яшьтән алып җиде яшькә кадәр) балалар булганда-20 кеше.
3.7. Өстәмә белем бирү педагогларына, тренер-укытучыларга:

15 кеше-шәһәр җирлегендәге белем бирү оешмаларында;

10 кеше - авыл җирендәге белем бирү оешмаларында.

## IV. Гомуми белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

1. Атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрнең эш хакы ставкасы өчен вазыйфаи окладык түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N} + P,$$

биредә:

$O_d$ -педагогик хезмәткәрләрнең эш хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән вазыйфаи окладыы;

$O_b$ -мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база окладының күләме;

$H_f$ -мәгариф оешмаларында хезмәткәрләр тарафыннан педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ -мәгариф оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең эш хакының әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән база ставкасы өчен сәгать нормасы;

P-китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә.

2. Мәгариф хезмәткәрләренең (әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән тыш), мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең гомуми белем бирү оешмаларында эш хакы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S + P,$$

биредә:

$O_d$ - гомуми белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$O_b$ гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база окладының күләме;

S-асылда эшләнгән вакыт (ставкасы);

P- китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш.

## V. Педагогик хезмәткәрләргә аудиториядән тыш эш белән мәшгульлек өчен түләүләр

1. Аудиториядән тыш эш белән мәшгульлек өчен түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

укучылар белән тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашыру өчен түләүләр;

язма эшләрне тикшерү өчен түләүләр (дәфтәрләрне тикшерү);

уку кабинетлары, уку остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр, укыту-тәҗрибә участоклары, музейлар белән идарә итү өчен түләүләр;

фән, методик яки цикл комиссиясе, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен түләүләр.

2. Укучылар белән тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашыру өчен түләүләр уку елы башына елга бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{kr} = A + K_r \times Y_k,$$

биредә:

$B_{nz}^{kr}$ - укучылар белән тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләү күләме;

А - укучылар белән тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләүләрнең даими өлеше;

$K_r$ - укучылар белән тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашыру өчен алмашынучан бер өлеше;

$Y_k$ -сыйныфта укучылар саны.

Тәрбия эшен оештыру һәм координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләүнең даими өлеше аена 550 сум тәшкил итә, күрсәтелгән функцияләрне тормышка ашырган өчен түләүләрнең алмаш өлеше аена 80 сум.

3.Язма эшләрне тикшерү өчен түләүләр (дәфтәрләрне тикшерү) түбәндәге түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{pt} = \left( \sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{pt},$$

биредә:

$B_{nz}^{pt}$ - язма эшләрне тикшерү өчен түләү күләме (дәфтәрләрне тикшерү);

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ - гомуми белем бирү оешмасында фән буенча педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ - гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан хезмәт күрсәтүнең факттагы саны;

$H_N$ - әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакын база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ -гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P- китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{pt}$ –язма эшләрне тикшерү өчен (дәфтәрләр тикшерү) өчен өстәмә түләү күләме 1нче таблицада китерелгән;

3.1. Педагогик хезмәткәр тарафыннан төрле сыйныфларда һәм төрле фәннәр буенча язма эшләрне тикшергәндә язма эшләрне тикшерү өчен түләү

күләме (дәфтәрләрне тикшерү) һәр фән һәм сыйныф буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

1 нче таблица

**Мәгариф оешмаларында язма эшләрне тикшерү (дәфтәрләрне тикшерү) өчен өстәмә түләүләр күләме**

| N т/б | Эш исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1. | Башлангыч сыйныфларда, рус теле һәм әдәбияты, туган тел һәм әдәбияты, математика фәннәреннән тикшерү | 12,0 |
| 2. | Чит тел буенча язма эшләрне тикшерү | 7,0 |
| 3. | Информатика, җәмгыять белеме, биология, химия, физика, география буенча язма эшләрне тикшерү | 3,6 |

4. Уку кабинетлары, уку остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр, укыту-тәҗрибә участоклары, гомуми белем бирү оешмаларында музейлар белән идарә иткән өчен түләү:

уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар белән идарә иткән өчен-444 сум;

уку-укыту остаханәләре, спорт заллары һәм уку - тәҗрибә участоклары белән идарә иткән өчен-833 сум.

Кабинетлар һәм укыту остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр белән эш итү булган укыту-методик, дидактик һәм күрсәтмә материалның белем бирү процессын җиһазландыруга карата расланган таләпләрнең 50 проценттан да ким булмавында уку кабинеты паспорты таләпләренә туры килү дәрәҗәсе белән билгеләнә.

4.1. Берничә уку кабинетының, уку остаханәләренең, спорт залларының, лабораторияләрнең, укыту-тәҗрибә участокларының, музейларның эшен тәэмин иткәндә күрсәтелгән эшне тәэмин иткән өчен түләү күләме һәр уку кабинеты, уку-укыту остаханәсе, спорт залы, лаборатория, укыту-тәҗрибә участогы, музей буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

5. Фән, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләргә җитәкчелек иткән өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{rk} = O_b \times D_{rk},$$

биредә:

$B_{nz}^{rk}$ - фән, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен түләү күләме;

$O_b$ – белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$D_{rk}$ - фән, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

5.1. Берничә комиссия, берләшмә белән җитәкчелек иткәндә, педагогик хезмәткәр тарафыннан түләүләр күләме күрсәтелгән очракта һәр комиссия, берләшмә буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

## VI. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

1. Стимуллаштыру характерендагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

1.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

белем бирү программасының үзенчәлеге өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;

юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

2. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, квалификация категориясенең гамәлдә булу срогы чикләрендә

гамәлдәге квалификация категориясе булганда, бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ – белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 2 нче таблицада китерелгән

2 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренең квалификация категориясенә өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләм, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | югары квалификация категориясе | 22,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |

| | | |
|---|---|---|
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 24,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

3. Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен хезмәткәрләргә түләүләр мәгариф оешмаларында аерым категория тәрбияләнүчеләр (укучылар) белән эшләгән өчен бирелә.

3.1. Педагогик хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{sop},$$

биредә:

$B_{sop}$ - белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмасы педагогик хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ - гомуми белем бирү оешмасының педагогик эшен алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ -гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

$H_N$ - әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән – гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакын база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ - – гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P-китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{sop}$ –белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме 3 нче таблицада китерелгән

3.2. Мәгариф хезмәткәрләре өчен (әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты белән билгеләнгән педагог хезмәткәрләрдән тыш) белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = O_d \times D_{sop},$$

биредә:

$B_{sop}$ - белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sop}$ - белем бирү программасы спецификасы өчен өстәмә түләү күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3.3. Белем алучыларның (тәрбияләнүчеләрнең) билгеле бер категорияләре булган мәгариф оешмаларында педагогик һәм ярдәмче хезмәткәрләр эшләгәндә белем бирү программаларының үзенчәлеге өчен берничә нигез буенча түләүләр бирү күздә тотыла. Бу очракта белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр күләме һәр нигез буенча исәпләнә.

3.4. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазифасында конкрет эш шартларын исәпкә алып, белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган профсоюз органы яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле орган белән килештереп, һәр оешмада раслана.

3 нче таблица

**Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме**

| N т/б | Белем бирү программасының спецификасы өчен өстәмә түләү билгеләү нигезе | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|---|
| | | һөнәри квалификация төркеме исеме | квалификация дәрәҗәсе | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 1 |
| 1. | Интернаты булган белем бирү оешмаларында эшләү | беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче | 1. |
| | | икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче - икенче | |
| | | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | |
| | | структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - икенче | |
| 2. | Лицей, гимназия классларында эшләү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 2. |
| | | структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - икенче | |
| 3. | Психологик-педагогик һәм медик-педагогик комиссияләрдә, логопед пунктларында эшләү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | икенче - дүртенче | 3. |
| 4. | Авыл җирендә һәм | педагогик хезмәткәрләр | 4 | 4. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныфларда рус телен һәм әдәбиятын укыту | вазыйфалары | | |
| | | структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - икенче | |
| 5. | Авыл җирлегендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан рус булмаган мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларны рус теленә өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче - дүртенче | 5. |
| 6. | Белем бирү оешмаларында туган телне (татар, чуаш, мари һ. б.) һәм әдәбиятны укыту | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 6. |
| | | структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | берече | |
| 7. | Балаларны туган тел (татар, чуаш, мари һ. б.) белән рус телендә белем бирүче мәктәпкәчә төркемнәрдә телгә өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче - дүртенче | 7. |
| 8. | Чит телләрне тирәнтен өйрәнүле белем бирү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 8. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | оешмаларында чит телләрне гамәли эштә куллану | структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - икенче | |
| 9. | Белем бирү оешмаларында һәм мәктәпара укыту комбинатларында эшләү | гомуми, төп гомуми һәм урта белем, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча өстәмә белем бирү белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | берече | 9. |
| | | | икенче | |
| | | | өченче | |
| 10. | "Кадетлар корпусы" статусына ия белем бирү оешмаларында эшләү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | 10. |

2. Россия Федерацисе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союз һәм автоном республикалар һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәр квалификация төркеменә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи окладына;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе Мәгариф министры) боерыгы белән Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибенә ярашлы рәвештә билгеләнә.

Татарстан Республикасының "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасының "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе булган өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән.

4.1. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган мәгариф хезмәткәрләренә аларның булуы өчен, түләү мәгариф хезмәткәре сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

5. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр юнәлеш буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри-квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә эш төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ - юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

**Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.**

| Һөнәри-квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче - икенче | 4 тән 10 елга кадәр | 1,0 |
| | | 10 нан15 елга кадәр | 2,0 |
| | | 15 елдан артык | 3,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | 2 дән 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 дан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10нан 15 елга кадәр | 3,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - өченче | 2 дән 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 дан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 нан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

5.1. Эш стажы үзгәргәндә, юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү), эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешкән көннән алып, стажын раслый торган документлар оешмада булса яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

5.2. Мәгариф һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкче һәм методик эш педагогик эш стажына керә һәм 5 нче таблица нигезендә исәпләнә.

5 нче таблица

**Эш вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган учреждениеләр, оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге**

| Оешма һәм учреждение исеме | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары, югары урта хәрби белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү (квалификацияне күтәрү) оешмалары); социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары һәм оешмалары: бала йорты, балалар өчен: өлкәннәр өчен оешмаларда санаторийлар, клиникалар, | Укытучылар, мөгәлимнәр, дефектолог укытучылар, укытучы-логопедлар (логопедлар укытучы-оештыручыларга (тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакыру алды әзерлеге буенча); физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, җитештерү белеме осталары (шул исәптән транспорт чаралары йөртүчегә өйрәтү, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләү, язучы машиналарда эшләү һәм башка оештыру техникасында эшләү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструкторлар-методистлар, инструкторлар-методистлар |

| | |
|---|---|
| сырхауханәләр, хастаханәләр һ. б., шулай ук бүлекләр, балалар өчен палаталар | (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер укытучылар, өлкән әйдәп баручылар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (начальниклар, мөдирләр), уку-укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары (начальниклар, мөдирләр), җитештерү буенча (эш), чит тел буенча, җәйге укуга әзерлек буенча, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча, уку-укыту бүлеге мөдирләре (начальниклар): практика белән, укыту-консультация пунктлары, логопед пунктлары, интернатлар, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр, аларның эшчәнлеге методик тәэмин ителеш белән бәйле мәгариф (тәрбия) процессы; режим буенча өлкән дежурныйлар, аккомпаниаторлар, культоештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы |
| Барлык төрдәге методик (уку-укыту-методик) оешмалар (кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, мөдирләре: секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр; эшчәнлеге методик тәэминатка бәйле булган фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспектор, методик вазыйфалар, инструктор вазыйфалары, шулай ук башка вазыйфалар (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле эш, төзелеш, тәэмин итү эшләрен башкару вазыйфалары белән бәйле эштән тыш) |
| Производствода кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү | Квалификацияне күтәрү һәм әзерләү мәсьәләләре белән бәйле булган штат укытучылары, производствода эшчеләрне |

| | |
|---|---|
| мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмалар, министрлыклар (ведомстволар) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре (бюролары) | производствога өйрәтү мастерлары, җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |
7. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация тасвирнамәләре нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тотучы мәгариф оешмаларында медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$ – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 5 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

5 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме , процентларда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |

| | |
|---|---|
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

8. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен түләүләр мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

биредә:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаи окладлы;

$D_{sd}$ –- эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме  6 нчы таблицада китерелгән.

8.1. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган медицина хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге, профсоюз органы яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

6 нчы таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме**

| N т/б | Эшчәнлек үзенчәлег өчен өстәмә түләү билгеләү нигезе | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләү | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 12 |
| | | табиблар һәм провизорлар | 5 |

9. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр медицина хезмәткәрләренең һәм фармацевтика хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном Республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелгән.

9.1. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә, түләү хезмәткәр сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

10. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр, юнәлеш буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж төркемнәре буенча медицина хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

биредә:

$B_{sr}$ - юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр;

$O_d$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ –юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме7 нче таблицада китерелгән

7 нче таблица

**Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

10.1. Эш стажы үзгәргәндә, юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү) стажы үзгәргәндә, профиль буенча эш стажы өчен

түләүнең күләмен арттыруга хокук бирә торган, документлар оешмада булса яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып башкарыла.

11. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

биредә:

$B_{sr}$ - хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

$O_d$ -мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладыы;

$D_{sr}$ –хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме 8 нче таблицада китерелгән

8 нче таблица

**Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү диапазоны, процентларда |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | икенче | 1,5 |
| | өченче | 3,0 |
| | дүртенче | 4,5 |
| | бишенче | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | берене - икенче | 5,0 |

12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгы эчендә хезмәт нәтиҗәләре буенча төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерийны оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең

нәтиҗәлелеген бәяләү критериеларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тәшкил итә

12.1. Оешма хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары профсоюз органы белән килешенеп оешма җитәкчесе тарафыннан раслана. Оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критериелары күрсәткечләре һәм түләүләрне башкару шартлары оешма алдында куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

12.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрнең күләмнәре, аларны башкару тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнә.

12.3. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\Sigma_{i=1}^{n}\Sigma_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \Sigma_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

биредә:

$B_{kj}$ - j-е хезмәткәренә башкарылучы эшләрнең сыйфаты өчен түләү;

$FOT_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$ - j-е хезмәткәре буенча эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие үрнәкләнгән;

$K_i$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие үлчәү коэффициенты;

n - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләре саны.

12.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеларын нормалаштыру төрле күрсәткечле нәтиҗәлелек критериеларының нисбәтлеген тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие (иң яхшысы һәм иң начары) күрсәткечләре диапазонын сайлап алудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль күрсәткеченә, икенчесе - бергә тигез. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып бергә кадәр булган күрсәткеч белән бирелә. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булган очракта, нормалаштырылган критерийның күрсәткече 0, иң яхшысыннан югарырак булганда -1 дип кабул ителә.

12.5. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие күрсәткеченең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткеченә бәйле булуы турыдан-туры (уңай динамика критерий күрсәткеченең артуы белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий күрсәткеченең кимүе белән билгеләнә) булырга мөмкин.

12.6. Нормалаштырылган критерий, әгәр аның күрсәткече критерий күрсәткеченә турыдан-туры бәйле булса, түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

Ii - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие;

FIi - эшчәнлек нәтиҗәлелегенең фактагы мәгънәсе;

Mi - эшчәнлек нәтиҗәлелегенең иң яхшы критерие;

Li - иң начар критерий эшчәнлеге.

12.7 Нормалаштырылган критерий, әгәр аның күрсәткече критерий күрсәткеченә кире бәйле булса, түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

биредә:

$I_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие;

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелегенең фактагы мәгънәсе;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелегенең иң яхшы критерие;

$L_i$ - иң начар критерий эшчәнлеге.

12.8. Үлчәү коэффициентлары белән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның өстенлек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырмача үлчәү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә:

$K_i$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие үлчәү коэффициенты;

$VK_i$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие үлчәү коэффициенты.

12.9. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң югары күләме 9 һәм 10 нчы таблицаларда китерелгән.

9 нчы таблица

**Мәгариф оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Әйдаман | 5 |
| 1.2. | Тәрбияче ярдәмчесе | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме. | | |
| 2.1. | Кече тәрбияче | 35 |
| 3. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1. | Физик культура буенча инструктор | 45 |
| 3.2. | Музыкаль җитәкче | 45 |
| 3.3. | Өстәмә белем бирү педагогы | 50 |
| 3.4. | Тәрбияче | 55 |
| 3.5. | Методист | 55 |
| 3.6. | Педагог-психолог | 55 |
| 3.7. | Өлкән тәрбияче | 60 |

| | | |
|---|---|---|
| 3.8. | Өлкән методист | 60 |
| 3.9. | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | 60 |
| 3.10. | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.11. | Логопед-укытучы(логопед) | 60 |
| 4.Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 4.1. | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә (бүлек, лаборатория, бүлекчә, сектор, укыту консультация пункты, укыту җитештерү остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр) мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 65 |
| 4.2. | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту-җитештерү остаханәсе, уку-укыту (уку-җитештерү) остаханәсе, уку-укыту хуҗалыгы башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) һәм башкалар идарәчесе): башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең (бүлекчәсенең) кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, уку (уку-җитештерү) остаханәсе, уку-укыту хуҗалыгы һәм башка структур бүлекчәләре (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 70 |

10 нчы таблица

**Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме. | | |
| 1.1. | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 5 |
| 2. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.1. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 35 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.2. | Диета буенча шәфкать туташы | 37 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.3. | Шәфкать туташы | 40 |
| 2.4. | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | 40 |
| 2.5. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.6. | Фельдшер | 45 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.7. | Өлкән шәфкать туташы | 50 |
| 3. Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 3.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән | 60 |

| | | |
|---|---|---|
| | табиб-белгечләрдән тыш) | |

12.10. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары, аларның үлчәү коэффициентлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлы тарафыннан раслана.

12.11. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру максатыннан түләүләр фонды төзелә, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times D_k,$$

биредә:

$FOT_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$FOT_{do}$ - төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча хезмәт өчен түләү фонды);

$D_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фондының өлеше.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителгән күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларыннан тыш) буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча хезмәт хакы түләү фондының 17,5 проценты күләмендә кабул ителә.

13. Премия һәм башка мактау характерындагы түләүләр белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә, юбилей даталары, аерым хөрмәтләү билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу һәм локаль актлар һәм оешманың коллектив килешүләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеләнгән вакыт (ай, квартал, ел) чорында төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларыннан тыш) буенча бер тапкыр билгеләнә.

13.1. Эш йомгаклары буенча премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, аларны бирү тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнә

13.2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме төп эш урыны һәм төп

вазыйфасы буенча хезмәткәрләргә кызыксындыру характерындагы түләүләр (хезмәт хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләү фондыннан кимендә 2 процент тәшкил итә

13.3. Премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге күрсәтмәсе белән расланган "Социаль өлкә тармакларында мәгариф һәм фәннең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр" чаралар планын ("юл картасын"), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 939-р номерлы күрсәтмәсе белән "2013-2018 елларга Татарстан Республикасында Мәгариф һәм фәннең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән социаль өлкә тармакларындагы үзгәрешләр" чаралар планы ("юл картасы") үтәгәндә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында бер үк вакытта билгеләнә ала.

## VI. Компенсация характерындагы түләүләр

1.Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында компенсация характерындагы түләүләргә түтәндәгеләр керә:

авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү;

хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берьюлы башкарганда, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр.

физик мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында эшләгән өчен компенсация характердагы түләүләр

2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары күмәк шартнамәләр, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә локаль норматив актлар белән билгеләнә

3.Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының, табибларның һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$B_{sm}$ -авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү;

$D_{sm}$ -авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү күләме, 1 388 сумга тигез күләм;

S- асылда эшләнгән вакыт (ставка)

Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә, шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә оештырылган түбәндәге шәһәр җирлекләрендә урнашкан мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә, шулай ук түләүләр бирелә:

Апас;

Балтач;

Байлар Сабасы;

Балык Бистәсе

4. Нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берьюлы башкарганда, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

биредә:

$B_{kh}$ -компенсация характерендагы түләүләр;

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

Dkh -Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация характерындагы өстәмә түләү күләме;

$D_{kh}$ - законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган асылда эшләнгән вакыт (ставка);

$H_{fk}$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең база оклады (хезмәт хакы ставкасы) өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгать нормасы.

5. Гадәти (төрле квалификация, һөнәр (вазыйфалар) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда, эш өчен түләүләр төнлә эшләү сәгате буенча нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда югарырак күләмдә, әмма законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмнәрдән түбән булмаган күләмдә билгеләнә.

Хезмәткәрне аңа график белән билгеләнгән ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткәндә эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә. Әгәр дә эш ял көнендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса, вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә – окладтан тыш кимендә берәр көндезге яки сәгатьләп түләнә торган база ставкасы күләмендә һәм, әгәр эш айлык нормадан тыш башкарылса, база окладыннан тыш кимендә икеләтелгән көндезге яки сәгатьләп түләнә торган ставка күләмендә түләнә.

5.1. Ял көне һәм эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәр теләге буенча аңа башка ял көне тәкъдим ителергә мөмкин. Бу очракта ял яки эшләми торган бәйрәм көне өчен бер тапкыр түләнә, ә ял көне өчен түләнми.

6. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән хезмәткәрләргә хезмәт хакы, окладлар (вазыйфаи окладлары),белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә база окладының 4 проценттан да ким булмаган күләмендә билгеләнә

7. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләүче мәгариф хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр бирелә.

7.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен, мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт хакы ставкасы өчен атнасына педагогик эш сәгатьләре нормалары өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{kh},$$

биредә:

$B_{kh}$ - сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләр (укучылар) белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

$O_b$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_f$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган факттагы хезмәт күрсәтүләр саны;

$H_N$ - әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакын база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P- китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{kh}$ – сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләр (укучылар) белән эшләгән өчен компенсацион характердагы түләүләр күләме, ул 11 нче таблицада китерелгән.

7.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләрне башкарганда, мәгариф хезмәткәрләре өчен (әлеге Нигезләмәнең 7.1 пункты белән билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән тыш) нормадан тайпылган шартларда эшләгәне өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times D_{kh},$$

биредә:

$B_{kh}$ - сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләү;

$O_d$ – мәктәпкәчә белем бирү оешмасында хезмәткәрләрнең хезмәт хакы;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләү күләме 11нче таблицада китерелгән

7.3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында педагогик һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең билгеле бер категорияләре белән эшләгәндә берничә нигез буенча компенсация характерындагы түләүләр бирү күздә тотыла, түләүләр күләме һәр нигез буенча исәпләнә.

7.4. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, компенсация характерындагы өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган профсоюз органы (яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклаучы вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр оешмада раслана.

11 нче таблица

**Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләү күләме.**

| N т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|---|
| | | һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Туберкулез интоксикациясе булган, ишетү буенча мөмкинлекләре чикләнгән, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсеш тоткарланган, аутистик тайпылышлары, катлаулы дефектлары булган һәм акылга зәгыйфь балалар | беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче | 7,0 |
| | | икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче - икенче | 7,0 |
| | | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче – дүртенче | 7,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (төркемнәрдә) эшләү | | | |
| 2. | Сөйләмдә авыр тайпылышлар булган балалар өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә төркемнәрдә эшләү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - өченче | 4,0 |

8. Аерым учреждениеләрдә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында эшләгән өчен компенсация характерын түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{khm} = O_d \times D_{khm},$$

биредә:

$B_{khm}$ - компенсация характерын түләү;

$O_d$ - медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{khm}$ - физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләгән өчен медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләү күләме, ул 15 процентка тигез.

## VII. Оешма җитәкчесенә , җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга хезмәт хакын билгеләү тәртибе

1. Оешма җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

2 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи оклады, гамәлгә куючы тарафыннан, хезмәт хакы буенча төркемгә карап, уку елы башына бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_d$ - мәктәпкәчә белем бирү оешма җитәкчесенең вазифаи оклады;

$O_b$ - җитәкченең төп оклад күләме;

S - асылда эшләнгән вакыт(ставка).

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркеме тәрбияләнүчеләрнең санына карап билгеләнә.

3. Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының җитәкче урынбасарларының һәм төп бухгалтерларының вазыйфаи окладлары әлеге оешмалар җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20 - 30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

4. Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең төп окладлары күләмнәре 12 нче таблицада күрсәтелгән.

5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирә ала. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ел нәтиҗәләре буенча мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен ай саен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр 12 нче таблицада бирелгән.

6. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе җитәкче урынбасарларына, мәктәпкәчә белем бирү оешмасының баш бухгалтерына, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели ала. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга

мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең югары чик дәрәҗәсе 70 процентына кадәр билгеләнә.

.

12 нче таблица

**Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең база окладлары һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме**

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләмле күрсәткечнең мәгънәсе (уку елы башына укучылар саны, тәрбияләнүчеләр саны буенча), кеше <*> | База оклады, сум | Стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 1 - 20 | 18 000 | 2 000 |
| 2 | 21 - 40 | 20 000 | 2 000 |
| 3 | 41 - 60 | 24 000 | 3 000 |
| 4 | 61 - 80 | 25 000 | 4 000 |
| 5 | 81 - 100 | 28 000 | 5 000 |
| 6 | 101 - 140 | 30 000 | 6 000 |
| 7 | 141 - 180 | 33 000 | 7 000 |
| 8 | 181 - 220 | 36 000 | 8 000 |
| 9 | 221 - 280 | 37 000 | 9 000 |
| 10 | 281 - 320 | 38 000 | 10 000 |
| 11 | 321 - 360 | 38 000 | 11 000 |
| 12 | 360 и югары | 39 000 | 12 000 |

--------------------------------

<*> Җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына

7. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчылары эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары һәм аларның үлчәү коэффициентлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.

8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерендагы түләүләр, аларның эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_C \times K_{VK},$$

биредә:

$B_k$ - стимуллаштыру характерендагы түләүләр,;

$B_C$ - әлеге Нигезләмәнең 12 нчы таблицасында китерелгән стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме;

$K_{VK}$ - сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

9. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында учреждение җитәкчесе, аның урынбасарлары, баш хисачысы өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VIII. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе

1.Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына мәктәпкәчә белем бирү оешмасының нормативлар, күрсәтелә торган хезмәтләрнең саны нигезендә билгеләнгән акчалар күләме чикләрендә тормышка ашырыла һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылыш таба.

Зеленодольск муниципаль районы
мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары турында
нигезләмәгә карата
1 нче кушымта

**МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРУ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ТИЕШЛЕ ТҮЛӘҮЛӘР АЛЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРҮЧЕ ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ВЕДОМСТВО БҮЛӘКЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ**

| N т/б | Дәүләт бүләге исеме |
| --- | --- |
| 1 | 2 |
| Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союз һәм автоном республикалар дәүләт бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациянең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең халык укытучысы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәбе хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган производство белеме мастеры |
| 1.6. | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.8. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.9. | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | СССРның халык укытучысы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5. | РСФСРның Атказанган тренеры |
| 3.6. | РСФСРның Атказанган укытучысы |
| 3.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |

| | |
|---|---|
| 3.9. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10. | Атказанган укытучы |
| 3.11. | Югары мәктәпнең Атказанган хезмәткәре |
| 3.12. | Атказанган халык мәгариф хезмәткәре |
| 3.13. | Югары мәктәпнең Атказанган эшлеклесе |
| 3.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик РеспубликаларСоюзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8. | Югары мәктәпнең Атказанган хезмәткәре |
| 4.9. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.11. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Татарстан Республикасының халык укытучысы |
| 5.2. | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3. | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 5.4. | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5. | Татарстан Республикасын югары мәктәбенең Атказанган хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 5.6. | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 5.7. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8. | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясе гомуми белем бирүнең мактаулы хезмәткәре. |
| 1.2. | Россия Федерациясе башлангыч һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясе урта һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең мактаулы фән һәм техника хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстерү өчен |
| 1.8. | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 2. Халык мәгарифе министрлыгы, СССР Мәгариф министрлыгы (РСФСР) | |
| 2.1. | СССРның мәгариф отличнигы |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе |
| 2.3. | “СССР һөнәри-техник белем отличнигы " билгесе |
| 2.4. | “РСФСР һөнәри техник белем отличнигы " билгесе |
| 2.5. | "Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем отличнигы " билгесе |
| 2.6 | «Мәгариф отличнигы» значогы; |

Зеленодольск муниципаль районы
мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары турында
нигезләмәгә карата
2 нче кушымта

**СТИМУЛ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР БИРЕЛӘ ТОРГАН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДАГЫ СОЮЗДАШ ҺӘМ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ**

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына карата кушымта
01.09.2020ел №1607

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫ
ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ
ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирүче мәгариф

| N т/б | Дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациянең мактаулы исемнәре. | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2.Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалары Союзынең мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның халык табибы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындгыа союздаш Республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Халык табибы |
| 4.2. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган табиб |
| 4.4. | Атказанган провизор |
| 4.5. | Атказанган фармацевт |
| 5. Советлар Союзы Социалистик Республикалар составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.2. | Атказанган табиб |

оешмаларында хезмәткәрләрнең хезмәт хакын түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт түләү системасы хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база (вазыйфаи) окладлары күләмнәрен дә кертеп, билгели торган нормалар җыелмасы, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

база оклады- оешма хезмәткәренең календарь ае өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен яисә хезмәт нормасы (хезмәт хакы нормасы) өчен билгеләнгән, башкарыла торган эшләрнең авырлыгына бәйле рәвештә, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпкә алмыйча оклад, хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - хезмәткәрләренең хезмәт (вазыйфаи) бурычларын, компенсация, стимуллаштыра торган һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, асылда эшләнгән вакыт өчен, календарь ае өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

эш хакы (хезмәткәрнең хезмәт хакы) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм эшнең шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре

компенсация характерындагы түләүләр - өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы бүтән түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка стимуллаштыра торган түләүләр.

3. Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең, физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, авыл хуҗалыгы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният

хезмәткәрләре, физик культура хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре) Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында (алга таба - өстәмә белем бирү оешмасы) хезмәт хакы (хезмәткәр хезмәте өчен түләү) түбәндәге очраклардан чыгып билгеләнә:

вазыйфаи окладлары;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

компенсация характерендагы түләүләр .

4. Хезмәткәрнең юнәлеш буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем алу турында документлар торгызылуга, квалификация категориясе бирүгә, мактаулы исем бирүгә, ведомство билгеләре белән бүләкләүгә бәйле рәвештә хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә, еллык яисә башка отпускта булган чорда, аның вакытлыча хезмәткә яраксызлыгы чорында, шулай ук аның дәвамында уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда, аның хезмәте өчен түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәрә.

5. Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

педагогик хезмәткәрләрнең белеме турындагы документларны (белгечлек буенча эш, билгеле бер вазыйфада,) һәм аларның стажын һәм педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (вазыйфаи окладлары) күләме билгеләнә торган башка дәлилләрне тикшерәләр;

ел саен өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

6. Өстәмә белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы:

уку елы башына өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә ел саен хезмәт хакын раслый;

өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяли, алар нигезендә аларга стимуллаштыру түләүләрен билгели.

## II. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең хезмәт хакының база окладларын билгеләү

1. Өстәмә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Укыту бүлеге секретаре | 9 489 | 9 868 | - |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт белеме буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| Икенче | Тренер-укытучы | - | 11 687 | 14 220 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | | | |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | | | |
| | Оештыручы педагог | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| | Методист инструктор | - | - | 14 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Производствога өйрәтү мастеры | - | 11 693 | 14 232 |
| | Педагог-психолог | | | |
| | Методист | - | - | 14 232 |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | | | |
| | Өлкән тренер-укытучы | | | |
| | Өлкән методист инструктор | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы (профессор-укытучылар составына кертелгән укытучылар вазыйфаларыннан тыш | - | 11 695 | 14 236 |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Өлкән методист<br>Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | - | - | 14 236 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлек, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | - | - | 14 301 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | - | - | 14 364 |

2.Өстәмә белем бирү оешмаларында физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме , сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 9 489 | | |
| | I группа инвалид спортчыны озатып йөрүче | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 9 489 | - | - |
| | Әйдәп баручы спортчы | | | |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура буенча инструктор | 9 489 | 11 680 | 14 200 |
| | Спрорт буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| | Спортчы-инструктор | 9 489 | | - |
| | Ат җайдагы тренере | 9 489 | 11 680 | - |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау технигы | - | 11 680 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура буенча инструктор-методист | - | 11 687 | 14 220 |
| | Җайлаштырылган физик культура буенча тренер-укытучы | - | 11 687 | 14 220 |
| | Хореограф | - | 11 687 | 14 220 |
| | Җайлаштырылган физик культура буенча өлкән инструктор-методист | - | 11 693 | 14 232 |
| | Физкультура-спорт оешмалары өлкән | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | инструктор-методисты | | | |

3. Өстәмә белем бирү оешмаларында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме , сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | - | 9 956 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация)) | | | |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
